Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Бишмунча авыл җирлеге Башкарма комитеты

КАРАР

8 апрель 2026 ел №4

Әлмәт муниципаль районы Бишмунча авыл җирлеге Башкарма комитетының аерым карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында

Россия Федерациясе Хезмәт кодексы нигезендә, хокукый мониторинг нәтиҗәләре буенча

Бишмунча авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Бишмунча авыл җирлеге Башкарма комитетының карарларының үз көчләрен югалтуын танырга:

- 2015 елның 20 ноябрендәге 9 номерлы «Муниципаль учреждение җитәкчесе, шулай ук муниципаль учреждение җитәкчесе вазыйфасына эшкә керүче зат тарафыннан үз керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында һәм үз иренең (хатынының) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү Кагыйдәләре хакында»;

- 2020 елның 14 маендагы 3 номерлы Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Бишмунча авыл җирлеге башкарма комитетының 2015 елның 20 ноябрендәге 9 номерлы «Муниципаль учреждение җитәкчесе, шулай ук муниципаль учреждение җитәкчесе вазыйфасына эшкә керүче зат тарафыннан үз керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында һәм хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү Кагыйдәләре хакында» карарга үзгәрешләр кертү турында»;

2. Әлеге карарны Әлмәт районы, Бишмунча авылы, Совет урамы, 57а йорт, Кама – Елга авылы, Кама – Елга урамы, 26а йорт, Ак – Чишма авылы, Ак – Чишма урамы, 1 йорт, Бахчасарай авылы, Җиләкле урамы, 1 йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендында халыкка игълан итәргә, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайты «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Бишмунча авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе М.Т.Мөбәрәкшин